СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

02.04.2018　　　　д. им. М. Вахитова　　　　№ 41-184

2017 нче елда Вахитов авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында

Вахитов авыл җирлеге башлыгы М. К. Идиятуллинның 2017 нче елда Вахитов авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында отчетын тыңлаганнан соң,

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында 2017 елда гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында отчетны игътибарга алырга.
2. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү, гражданнарны шәхси кабул итү тора дип билгеләргә.
3. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау, шул исәптән гражданнарның шикаятьләре һәм мөрәҗәгатьләре буенча законлы һәм нигезле карарлар кабул итү тәртибен үтәү эшен дәвам итәргә.
4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　М.К. Идиятуллин